Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Полянка авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 1**

Полянка авылы 2019 елның 05 февраль

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянкаавыл җирлеге Советының 2014 елның 10 октябрдәге “Җир салымы турында” 20 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 29 сентябрендәге “Россия Федерацисе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында” 325-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Уставына таянып,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советының “Җир салымы турында” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советының 2014 елның 18 ноябр 24 номерлы, 2015 елның 29 май 9 номерлы, 2017 елның 23 август 6-4 номерлы, 2019 елның 13 июн 7-3 номерлы, карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән гайре)яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуальторак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән гайре)җир кишәрлекләренә карата -0,3%”

2.Әлегекарарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Полянка җирлегенең Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы, Полянка авылы адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәмТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контроль лекитүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Полянка авыл җирлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы
тоташу ноктасына кадәр уза.
ТР муниципаль районы Башлыгы Р. А. Сираев

СОВЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000891 ПОЛЯНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ СОВЕТЫ